УДК 398

*Л.Х. Дәүләтшина*

# БАШКОРТСТАНДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАРНЫҢ ФОЛЬКЛОР МИРАСЫН ӨЙРӘНҮДӘ РИФ МӨХӘММӘТҖАНОВ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье дается характеристика исследовательской деятельности фольклориста Р.М. Мухаметзянова, описываются вехи его творческого пути. Автор статьи уделяет особое внимание работам фольклориста в области татарского обрядового фольклора, которые представляют собой систематизированный исследовательский материал по фольклору татар, проживающих на территории Республики Башкортостан. Анализ работ автора позволил сделать выводы об уникальности его находок и представить некоторые из них на суд читателя.

**Ключевые слова:** фольклористика, обрядовый фольклор, фольклорист, свадебный фольклор, обряд, ритуал.

The article describes the research activities of folklorist R.M. Mukhametzyanov, describes the milestones of his creative path. The author of the article pays special attention to the works of a folklorist in the field of Tatar ritual folklore, which are systematic research material on the folklore of Tatars living in the territory of the Republic of Bashkortostan. Analysis of the author’s works made it possible to draw conclusions about the uniqueness of his finds and submit some of them to the reader’s court.

**Keywords:** folkloristics, ritual folklore, folklorist, wedding folklore, rite, ritual.

Күренекле фольклорчы-галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗановның исеме татар фольклористикасы тарихына, халкыбыз күңеленә мәңгегә уеп язылган. Балачагыннан ук халык иҗаты белән тирәнтен кызыксынган яшь галим Башкортстанда яшәүче милләттәшләребезнең рухи мирасын барлау һәм өйрәнү эшенә 1960 еллар урталарыннан соң җиң сызганып тотына һәм тиз арада фән даирәсендә тирән ихтирам казана. 1980 еллар азагында илдә милли үзаң күтәрелеше башлангач, Риф Мирхәбибулла улы читтә калмый, Башкортстан Республикасында яңа оешкан татар милли хәрәкәтендә әйдәп баручыларның берсе, Башкортстан Татар иҗтимагый үзәгенең Гали мәҗлес әгъзасы, «Алтын ай» милли агарту фондының җитәкчесе дәрәҗәсендә хезмәт куя. Шул ук вакытта галим фән өлкәсендә дә тынгысыз эшен дәвам итә. Аның хезмәтләре бүген дә меңнәрчә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар тарафыннан җентекләп өйрәнелә, димәк, галим әле дә халык хәтерендә яши, аның уйлары фикердәшләрен таба, китаплары фольклорчыларның китап киштәсендә кадерләп саклана...

Риф Мирхәбибулла улының исеме, гыйльми язмалары, китаплары Башкортстанда яшәүче татарлар өчен аеруча газиз һәм якын, чөнки галим бар гомерен туган як халкының рухи мирасын барлау

һәм өйрәнүгә, аны саклап калуга, тирә-якта популярлаштыруга багышлаган. Ә бу исә галимнең телче дә, әдәбиятчы да, тарихчы да, этнограф та булуын сорый, чөнки халык иҗатын тирәнтен аңлау, халыкның никадәр бөек булуын тану өчен, телне бар нечкәлекләре белән тоеп, халык иҗатында чагылыш тапкан теге яки бу үзенчәлекнең ничек, каян барлыкка килүенә төшенә, халык күңелен бер сүздән, ымнан, хәрәкәттән аңлый белергә кирәк.

Татар йола фольклорын фәнни яктан тирәнтен анализлаган, йола иҗатына караган аерым жанрларның үзенчәлекләрен билгеләгән хезмәтләр арасында Риф Мөхәммәтҗанов китаплары аерым урын алып тора. Ул – Татарстаннан читтә, Башкортстан территориясендә гомер итүче татарларның халык авыз иҗатын, шул исәптән календарь һәм гаилә-көнкүреш йола фольклорын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү эшен башлап җибәргән беренче галим. 1960 – 1990 елларда галим Башкортстан Республикасының татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, йөзләрчә авылны урап чыга. Әлеге экспедицияләрдә җыелган фольклор материаллары тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә. Югарыда аталган «Татар халык иҗаты» унөчтомлыгының һәр китабында диярлек Риф Мирхәбибулла улы тарафыннан тупланган халык авыз иҗаты үрнәкләре урын ала.

Ык буена урнашкан татар авылларында таралган йолаларны, гореф-гадәтләрне өйрәнүгә ул аерым игътибар бирә, экспедицияләр барышында туплаган мәгълүматлары нигезендә 1973 елда филология фәннәре докторы, профессор Әхнәф Кирәев җитәкчелегендә «Башкортстан Ык буе татарларының йола поэзиясе» темасына кандидатлык диссертациясен [Мухаметзянов, 1973] яклый. «Әлеге хезмәт Татарстаннан читтә яшәүче татар халкының, аерым алганда, Башкортстанда яшәүче татарларның, милли фольклорын, аның төбәк үзенчәлекләрен, биредә яшәүче башка халыкларның авыз-тел иҗаты белән бәйләнешен чагыштырма планда, комплекслы һәм системалы рәвештә анализлаган беренче гыйльми тикшеренү булып тора» [Фазлетдинов, 2021, б. 6]. Аның концептуаль фикерләре соңрак Ф.И. Урманчеев, М.Х. Бакиров, Х.Ш. Мәхмүтов, К.М. Миңнуллин кебек галимнәрнең хезмәтләрендә үстерелде. Шул рәвешле, татар халкының йола фольклорын өйрәнү эше яңа баскычка күтәрелде, төрле кыйтгаларга сибелгән милләттәшләребезнең йола поэзиясен тулы һәм системалы итеп күзаллау, аның генетик тамырларын ачыклау мөмкинлеге туды.

Риф Мөхәммәтҗановның фәнни эзләнүләре бер урында тукталып калмый, алдагы елларда студентлар өчен дәреслекләр, уку кулланмалары формасын ала, фән даирәсендә тирән ихтирам казана. 1977 елда аның – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе» [Мөхәммәтҗанов, 1977], 1982 елда – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия» [Мөхәммәтҗанов, 1982], 1984 елда рус телендә «Специфика татарских фольклорных

жанров» [Мухаметзянов, 1989] дип аталган хезмәтләре үзе эшләгән Башкорт дәүләт университеты нәшриятында дөнья күрә. Бу хезмәтләр бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганак булып кала. Йола фольклорын өйрәнүгә багышланган әлеге хезмәтләрендә галим Ык буенда яшәүче татар халкының йола поэзиясен ике төргә бүлеп тикшерә, календарь һәм туй поэзиясе жанрларының яңа классификациясен тәкъдим итә, аларны Татарстанда яшәүче татарларның фольклоры белән тарихи-чагыштырма планда анализлап, уртак һәм аермалы якларын билгели, шул ук вакытта, Башкортстанда яшәүче татарларның гомумтатар халкының аерылгысыз өлешен тәшкил итүен ассызыклый.

Р. Мөхәммәтҗанов хезмәтләренең тагын бер үзенчәлекле һәм әһәмиятле ягы шунда: ул йола фольклорының синкретик табигатенә игътибар итү белән берәттән, йола үткәргәндә көйләнә, сөйләнә торган тезмә һәм чәчмә тел калыпларын йола комплексының аерылгысыз өлешен тәшкил иткән хәрәкәт-гамәлләр белән бергә өйрәнүне бердәнбер дөрес юл дип билгели. Йола комплексындагы «сүз материалы йолалардагы ритуал хәрәкәт символлары белән тыгыз бәйләнештә тора, дөресрәге аларның символик мәгънәсен ачып сала. Йоладан башка бу сүз материалының әһәмияте югала, ритуал хәрәкәтләрнең гомум контекстында гына ул тулы мәгънә ала» [Мөхәммәтҗанов, 1982, б. 9], – дип яза Р. Мөхәммәтҗанов, шуңа күрә аның һәрбер хезмәтендә йола поэзиясе үрнәкләре этнографик контексттан аерылмый, бербөтен рәвешендә тәкъдим ителә. Билгеле бер йола дәвамында башкарылган хәрәкәтләр җыелмасын, йоланың башкарылу урынын, вакытын, магик нигезен исәпкә алганда гына йола фольклоры үрнәкләренең эчтәлеген, мәгънәсен, вазифаларын аңларга һәм ачарга мөмкин, чөнки әлеге текстлар халык мәдәниятендә мөстәкыйль рәвештә кулланылмый, бары йола комплексы эчендә генә яши. Галимнең хезмәтләрендә кызыл җеп булып сузылып барган әлеге фикер бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмый, киресенчә, фольклористика фәненең этнографик тикшеренүләр белән параллель алып барылырга тиешлеген нигезли һәм аның өйрәнү объектын киңәйтә.

Р. Мөхәммәтҗанов хезмәтләрендә йола фольклорының аеруча киң яктыртылган төрләренең берсе – туй йолалары, моның сәбәбен ул туй иҗатының йола поэзиясенең иң нык сакланган өлеше булуы белән аңлата. Галим билгеләвенчә: «Туй йолаларының төп юнәлеше һәм составы бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Калган бөтен эшләр (башта, озатканда, соңыннан булган чаралар) һәммәсе дә әлеге үзәк акт – ярәшелгән кызны күчерү – тирәсенә тупланган. Бу күпчелек халыкларда, шул исәптән, татарларда да, шулай булган һәм берничә көнгә, аерым урыннарда ай, хәтта елга сузылган. Шуңа күрә ул ифрат катлаулы фольклор-этнографик комплекс барлыкка китергән» [Мөхәммәтҗанов, 1977, б. 11].

Татар халкының традицион мәдәниятендә өйләнешү-кияүгә чыгуның өч төре формалашкан булган: 1) кыз урлап өйләнешү, 2) кызның егеткә үзе ияреп китүе («ябышып» яки «качып чыгу»); 3) алдан килешеп, ягъни «ярәшеп-яучылап» өйләнешү. Өйләнешү төрләренең соңгысы иң төп һәм иң таралган традицион форма буларак характерлана, һәм хәзер дә ул заманага бәйле рәвештә үзгәреш кичергән булса да, төрле төбәкләрдә чәчелеп яшәгән татар халкы өчен хас булган гомуми структурасын саклап кала. Ык буе татарларының туй йола иҗатын анализлау барышында, Р. Мөхәммәтҗанов югарыда әйтелгән үзәк акт (ярәшелгән кызны күчерү) тирәсенә җыелган барлык элементларны (яучылау, ярашу, аклашу, туй алды күренеше, ак өйгә кыз күчерү, йола мунчасы, кыз-килен чәкчәге, кияү катламасы, кыз сырасы, кияү каршылау, яр-яр, никах, йола коймагы, кияү күрсәтү, килен төшерү, бүләк баглау, олы туй, туй арты ритуаллары) туплый һәм аларның магик, семантик һәм прагматик нигезен ачыклый.

Р. Мөхәммәтҗанов туй йоласының гомуми структурасын, аерым этапларын, аларның магик нигезен анализлаганнан соң, туй поэзиясенең жанр составын билгели һәм бүгенге көндә инде күбесе кулланылыштан төшеп калган үзенчәлекле текстларны (туй йола җырлары, сыктаулар, такмак-такмазалар, арбау-теләкләр, әйтешләр, таңкучатлар, баталар, яр-ярлар, типсәүләр, бит ачулар, самаклар һ. б.) укучыга тәкъдим итә, аларның жанр хасиятләре турында кызыклы фикерләрен җиткерә. Туй поэзиясенең күптөрле жанрлары арасыннан аның аерым игътибарын «Хан кызы, ач ишегең...» җыры җәлеп итә. Аның галим тарафыннан язып алынган тексты түбәндәге юллардан гыйбарәт:

*Егет:*
Хан кызы, ач ишегең,
Мин керәем.
Синең буең зифа диләр,
Мин күрәем.

*Кыз:*
Минем буем зифа булса,
Нә диярсең?
Бакчадагы алмагачны
Күрмәдеңме?

*Егет:*
Хан кызы, ач ишегең,
Мин керәем,
Синең йөзең нурлы диләр,
Мин күрәем.

*Кыз:*
Минем йөзем нурлы булса,
Нә диярсең?
Айның ундүрт кичәсени
Күрмәдеңме?

*Егет:*
Хан кызы, ач ишегең,
Мин керәем.
Синең тәнең йомшак диләр,
Мин күрәем.

*Кыз:*
Минем тәнем йомшак булса,
Ни диярсең?
Сатучыда ак мамыкны
Күрмәдеңме?

*Егет:*
Хан кызы, ач ишегең,
Мин керәем.
Синең тәнең ап-ак диләр,
Мин күрәем.

*Кыз:*
Минем тәнем ап-ак булса,
Ни диярсең?
Су өстендә ап-ак күбек
Күрмәдеңме?

Автор бу җырның прагматик функциясенә бәйле түбәндәге искәрмәне бирә: «Ык буе татарларында никахтан соң кияү кыз янына килгәч, кыз куенына керер алдыннан, алар арасында әйтеш башлана» [Мөхәммәтҗанов, 1989, б. 24]. Билгеле булганча, элекке заманнарда татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә кияү кыз янына барганда, кияү егетләре тарафыннан махсус җырлар башкарылган. Җирле үзенчәлекләргә бәйле рәвештә аларны төрлечә атап йөрткәннәр: «Кияү типсәү», «Уҗикарәм», «Шәмчырак» һ.б.

Кыз катына кигән кияүне кызның җиңгәләре, апа-сеңелләре, ахирәтләре төрле каршылыклар, сынаулар әзерләп көтеп торалар. Сынаулар капка төбеннән үк башлана, алга таба узар өчен, кияүдән капка бәясе / хакы сорыйлар. Капка хакы акча да, бүләк тә, шулай ук төрле табышмакларга җавап бирү дә булырга мөмкин. Өй эченә кергәч, кияүне *ишек бавы* дип аталган сынау да көтә. Бүгенге көндә дә өлешчә сакланып килгән бу йоланың тасвирламасын Г. Тукай язып калдырган: «“Кыз өе” дип аталган махсус урынга кияүне алып киләләр. Кыз үзенең иптәшләре белән бикләнеп чаршау эчендә утыра. Кияүне кертмиләр. Ул “Ишек бавы кыйбатмы?” – дип сорый. Ишек саклаучы ир балалар (алар арасында кызның энесе я башка ир туганы да була) бирәр хак әйтәләр, *“ишек бавы җырларын”* башкаралар. Кияү егетләре бу хакны кыйбатсына. Ике арада сатулашу башлана. Ахырда кияү килешенгән бәяне түли һәм ишек ачыла» [Тукай, 1975, б. 123 – 124].

Мәгънәсе белән ул шул ук йолага – ягъни егетнең кыз куенына керер алдыннан җыр башкару йоласына якын торган «Хан кызы...»

җырын Р. Мөхәммәтҗанов Ык буе татарлары арасында таралыш тапкан «кияү ябулар» жанры белән бәйли һәм аны, әлегәчә басылган хезмәтләрдә сүзгә алынмавы нәтиҗәсендә, җирле үзенчәлек булырга мөмкин дип фаразлый. Бүгенге көндә әлеге әйтеш, кызганычка каршы, кулланылыштан төшеп калган, әмма алдагы елларда үткәрелгән этномузыкологик эзләнүләрдә галимнәр бу текстның татар халкында киң таралыш тапкан булуын һәм Идел буе татарларының барлык этник төркемнәрендә дә язып алынуын нигезли [Исхакова-Вамба, 1997, с. 57]. Бу текстның жанр төренә карата галимнәр арасында фикер төрлелеге күзәтелсә дә, нигездә, күпчелек хезмәтләрдә аның туй поэзиясенә каравына шик белдерелми.

Р. Мөхәммәтҗанов хезмәтләрендә урын алган йола поэзиясе үрнәкләре, галимнең йола фольклорына караган саллы фикерләре, әлбәттә, биредә тәкъдим ителгән мәгълүмат белән генә чикләнми. Аның йола фольклоры өлкәсендәге китапларын һәм күпсанлы мәкаләләрен татар фольклористикасының иң кыйммәтле хәзинәләре исемлегенә кертергә мөмкин. Галимнең хезмәтләре бүгенге көндә дә актуальлеген һич югалтмый. Бер яктан, аларда үз заманасы өчен яңалык булып яңгыраган һәм хәзер дә әһәмиятен югалтмаган тирән фәнни фикерләр әйтелә. Икенче яктан, Р. Мөхәммәтҗанов тарафыннан тупланган һәм йола поэзиясенең төрле жанрларына караган фольклор текстлары XXI гасыр галимнәре өчен алтын бәһасенә тора, чөнки аларның күбесе сакланмаган, заманалар үзгәрү белән алар борынгы магик нигезен югалткан һәм тормыштан төшеп калган. Шуңа да Риф Мөхәммәтҗановның хезмәтләре татар фольклористикасы фәненең әһәмиятле өлешен тәшкил итә һәм үз тикшеренүчесен көтә, чөнки йола фольклоры – ышануларны, шигъри сүз тезмәләрне, калыплашкан хәрәкәт-гамәлләрне һәм халыкның күпгасырлык акыл тәҗрибәсен туплаган рухи мирас буларак, татар кешесен, кайсы гына төбәктә яшәвенә карамастан, туганнан алып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр озата бара һәм аның яшәү рәвешен билгели.

**Әдәбият**

*Исхакова-Вамба Р.А.* Татарское народное музыкальное творчество (Традиционный фольклор). Казань: Татар. кн. изд-во, 1997.

*Мөхәмәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе). «Татар халык иҗаты» курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы. Уфа, 1977. 11 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (туй поэзиясе). Уфа, 1989. 24 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Календарь поэзия: «Татар халык иҗаты» курсы буенча уку әсбабы. Уфа, 1982. 72 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Туй поэзиясе: «Татар халык иҗаты» курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы / фәнни редакторы Т.Н. Галиуллин. Уфа, 1977. 70 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының календарь йола иҗаты. Уфа, 1982.

*Мухаметзянов Р.М.* Обрядовая поэзия приикских татар Башкирии: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09. Уфа, 1973. 228 с. https://search.rsl.ru/ru/record/01009856164

*Мухаметзянов Р.М.* Специфика татарских фольклорных жанров: учебное пособие по спецкурсу. Уфа, 1989. 84 с.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 4 томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

*Фазлетдинов И.К.* Кереш // Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты / төз.: И.И. Ямалтдинов, И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘҺСИ, 2021. Б. 3–12.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми секретаре*